| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.08.2019 ел Баулы шәһәре № 247

2019-2020 уку елында Баулы
муниципаль районының
муниципаль белем бирү
учреждениеләре укучыларын
туклaндыруны тәэмин итү турында

Муниципаль мәгариф учреждениеләре укучыларын тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү, «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә укучыларны туклaндыруны оештыру» турында СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләрен (сәламәт туклануны оештыру өлешендә) үтәү максатларында, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесен Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Баулы муниципаль районы бюджетыннан район һәм шәһәр гомуми белем бирү учреждениеләрендә ташламалы шартларда кайнар аш белән тәэмин итүче предприятиеләргә субвенцияләр бирү буенча вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

2. 2019 елның 1 сентябреннән Баулы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениесендә уку чорына бер укучыга бер көнлек кайнар ризык бәясе күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

бюджет хисабына: 7,40 сум;

ата-аналар хисабына: шәһәрдә иртәнге аш - 15 сум, төшке аш – 35 сум, авылларда иртәнге аш - 15 сум, төшке аш - 25 сум.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ (Ганиева Д.З.) тиеш:

гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының төп туклыклы матдәләр балансы сакланган кайнар ашын оештырырга;

Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – ЕГИССО) кулланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә, әлеге хезмәтне күрсәтү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров